РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КОРСАБАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422051, Республика Татарстан,
Сабинский район,
с.Корсабаш, ул. Школьная, 28
тел. (84362) 2-27-49

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КУРСАБАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

422051, Татарстан Республикасы,
Саба районы, Курсабаш авылы,
Школьная урамы, 28 йорт
тел. (84362) 2-27-49

e-mail: korsab.sab@tatar.ru

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

29.06.2020 — № 21

Курсабаш авыл җирлеге Башкарма комитетының 25.04.2016 елның 19 нчы номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контролен тормышка ашырганда тикшерүләр үткәрүнең административ регламентын раслау турында" карарына үзгәрешләр кертү турында»

*Район прокуратурасының 19.06.2020 елның 02-08-02-82-2020 номерлы протесты* һәм "Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында" 02.12.2019 елның №390-ФЗ Федераль законы нигезендә Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Курсабаш авыл җирлеге Башкарма комитетының 25.04.2016 елның 19 нчы номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контролен тормышка ашырганда тикшерүләр үткәрүнең административ регламентын раслау турында» карары белән расланган муниципаль торак контролен тормышка ашырганда тикшерүләр үткәрү буенча административ регламентка түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.1 пунктны киләсе эчтәлектәге 3.1.1. пункты белән тулыландырырга:

“ 3.1.1. Планлы тикшерүнең еллык планына, планлы тикшерүләрне кертү өчен нигез булып,кабул иткән коннән бер ел үткәннән соң кертелә:

- дәүләт торак күзәтчелеге органына тапшырылган уведомлениегә туры китереп, торак милекчеләре ширкәте, торак, торак-төзелеш кооперативы яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы тарафыннан күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлау;

- социаль файдаланудагы беренче наемга алынган торак йортның муниципаль

реестрында, торак урыннарны наймлаучы булып торучы, эшчәнлеге тикшерелергә тиешле зат булган социаль файдаланудагы наемга алынган йортларның муниципаль реестрында исәпкә кую;

- юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата соңгы планлы тикшерүне үткәрү тәмамлануы;

- коммуналь ресурсларны (коммуналь хезмәтләрне) куллану нормативларын билгеләү һәм үзгәртү".

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә йөклим.

Курсабаш авыл җирлеге башлыгы: А.Р. Гыймадиев